| | |
|---|---|
| ГЛАВА МУРТЫШ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОРТЫШТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**02.11.2020 ел** **№ 2**

2021 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Мортыштамак авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Мортыштамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2020 елның 13 ноябрендә 11.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Мортыштамак авылы, Совет урамы, 47 нче йорт адресы буенча урнашкан Мортыштамак авылы Мәдәният йорты бинасында 2021 елда Сарман муниципаль районының Мортыштамак авылы җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнарның җыенын билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортларының студентларыннан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертүегез һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүегез белән килешәсезме:

1)Мортыштамак авылы Совет урамында урнашкан су башнясының хуҗалык корылмасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
2) янгын ранецлары (2 данә), су салу өчен емкость (1 т), янгын җиңсәләре (2 данә)сатып алу;
3)кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
4) Мортыштамак авылы территориясендәге чүп үләннәрен чабу һәм җыештыру (ягулык-майлау материаллары (бензин), хуҗалык эшләре өчен инвентарь (көрәк, тырма,сәнәк, себеркеләр) сатып алу;
5) Мортыштамак авылы Совет урамы буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (асфальт сатып алу ,ташу,чокырларга асфальт түшәп ремонтлау, асфальт җәю, эш өчен түләү);
6) Мортыштамак авылында Минзәлә елгасы аша салынган күперне ремонтлау (буяу сатып алу);
7) Мортыштамак авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
8) Мортыштамак авылы Совет урамында урнашкан зират территориясендәге биек агачларны, куакларны кисү, яшь үсентеләрдән чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);
9) ял итү зоналарын төзекләндерү (Мортыш елгасы һәм Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашлар өчен куелган обелиск янында эскәмияләр, урналар сатып алу һәм урнаштыру ;
10) яңа юл билгеләре урнаштыру өчен металл торбалар сатып алу;
11) Мортыштамак авылында спорт ярышлары уздыру өчен призлар, бүләкләр сатып алу

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Мортыштамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге башлыгы И.Н. Хадиуллин